**Республика Татарстан**
**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «15» апрель 2019 ел № 601

Питрәч муниципаль районының «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре» 1992 елның 9 октябрендәге 3612-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Мәдәният бүлеге» муниципаль бюджет учреждениесе уставы, «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы законы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 елның 8 маендагы 397 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Питрәч муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең түләүле хезмәтләр күрсәтү турында нигезләмәсен расларга.

2. «Питрәч муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең түләүле хезмәтләр күрсәтү прейскурантын расларга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы А. Ф. Фазылҗановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А. В. Хәбибуллин